КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 март

г.Казань

№ 324

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе турында» 2022 ел, 15 июнь, 557 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе турында» 2022 ел, 15 июнь, 557 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 30 гыйнвар, 78 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе турында нигезләмәнең 1.3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе составында:

комиссия составыннан М.Р.Хисамиевны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Шакиров Илнур Ирек улын | Департамент җитәкчесе урынбасарын – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының Гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек итү идарәсе башлыгын, Республика комиссиясе рәисе урынбасарын (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Бикеев Игорь Измаиловичны | «В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (ИИХИ)» югары һөнәри белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенең беренче проректорын, фәнни эшләр буенча проректорын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын (килешү буенча); |
| Сабурская Сәрия Харис кызын | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча); |

Тимур Җәүдәт улы Сөләймановның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесен, Балалар һәм яшьләрнең гомумроссия дәүләт иҗтимагый хәрәкәтенең төбәк бүлеге советы рәисен (килешү буенча)».

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 елга кадәр һәм перспективада 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының демографик үсеш комплекслы программасын раслау турында» 2009 ел, 12 гыйнвар, 6 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 елга кадәр һәм перспективада 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының демографик үсеш комплекслы программасын раслау турында» 2009 ел, 12 гыйнвар, 6 нчы карарына үзгәреш кертү хакында» 2011 ел, 12 июль, 562 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 елга кадәр һәм перспективада 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының демографик үсеш комплекслы программасын раслау турында» 2009 ел, 12 гыйнвар, 6 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 29 декабрь, 1054 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы карарының 1 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль ярминкә» коммерциягә карамаган оешмаларның Республика хәйрия фестивален оештыру һәм уздыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1321 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин